ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 04 2019 г. № 208

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 17 гыйнварындагы 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 17 гыйнварындагы 8 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (кушымта)».

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 гыйнварындагы 8 номерлы карары белән расланган (кушымта) бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган теркәлгән үзгәрешләрне расларга.

3. Җәмәгатьчелек һәм гаммәви мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ә.Хаҗиевкә йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 23-нче апрель
208-нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 елның 17 гыйнварындагы 8 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1. Регламентның «Стандартка таләпләрнең эчтәлеге» баганасының 1.1, 2.1 пунктларында исемендә «яшәү өчен һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле» сүзләрен «яшәү өчен, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты» сүзләренә алмаштырырга.

2. 1.4 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча Нигезләмәне раслау турында (алга таба – Нигезләмә)» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары (2018 елның 24 декабрендәге редакциядә) белән.

3. 1.5 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«Бакча йорты булып, мондый бинада аларның вакытлыча торуы белән бәйле, гражданнар тарафыннан көнкүреш һәм башка ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен билгеләнгән сезонлы куллану бинасы танила».

4. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«Бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану турында муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты – 45 календарь көн».

5. «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт» баганасының 2.4 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«Нигезләмәнең 59 пункты».

6. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5 пунктына «Нигезләмә билгеләгән таләпләр буенча» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану өчен кирәк:

а) бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану турында гариза, анда бакча йорты яки торак йортның кадастр номеры һәм бакча йорты яки торак йорт урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры, мөрәҗәгать итүченең почта адресы яки мөрәҗәгать итүченең электрон почтасы адресы күрсәтелә;

б) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан гариза бирүченең бакча йортына яки торак йортка теркәлгән хокуклары турында белешмәне үз эченә алган күчемсез милек объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында өземтә; яисә гариза бирүченең бакча йортына яки торак йортка милек хокукы Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән очракта, торак йортка яки бакча йортына милек хокукын билгеләүче документ яки мондый документның нотариаль расланган күчермәсе;

в) инженерлык эзләнүләре өлкәсендә үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзалары булган шәхси эшкуар яки юридик зат тарафыннан бирелгән, «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешендә, 7, 8 һәм 10 статьяларында билгеләнгән бакча йортының ышанычлылык һәм куркынычсызлык таләпләренә туры килүен раслый торган объектның техник торышын тикшерү буенча бәяләмә (бакча йортын торак йорт дип таныган очракта);

г) бакча йорты яки торак йортка өченче затларның хокуклары булган очракта - күрсәтелгән затларның бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану өчен нотариаль расланган ризалыгы.

Гариза бирүченең теләге буенча шулай ук гаризалар, хатлар, гражданнарның канәгатьсез яшәү шартлары турында шикаятьләре тәкъдим итөлергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

- шәхси (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат);

- почта аша җибәрү.».

7. «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт» баганасының 2.5 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«Нигезләмәнең 56 пункты».

8. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«Бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

а) мөрәҗәгать итүче тарафыннан Нигезләмәнең 56 пунктындагы «а» һәм (яки) «в» пунктчаларында каралган документларны тапшырмау;

б) җирле үзидарәнең вәкаләтле органына гариза бирүче булмаган затның бакча йортына яисә торак йортка теркәлгән милек хокукы турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында булган мәгълүматлар керү;

в) әгәр Нигезләмәнең 56 пунктындагы «б» пунктчасында каралган хокук билгеләүче документ яисә мондый документның нотариаль расланган күчермәсе гариза бирүче тарафыннан күрсәтелмәгән булса, җирле үзидарәнең вәкаләтле органына бакча йортына яисә торак йортка теркәлгән милек хокукы турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында мәгълүматлар булмау турында хәбәрнамә керү.

Әлеге нигез буенча бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту шул очракта мөмкин, әгәр җирле үзидарә органы Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында бакча йортына яки торак йортка теркәлгән хокуклар булмау турында хәбәрнамә алганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә мондый хәбәрнамә алу турында гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр иткән булса, Нигезләмәнең 56 пунктындагы «б» пунктчасында каралган хокук билгеләүче документ яки мондый документның нотариаль таныкланган күчермәсен тапшырырга тәкъдим итсә, һәм мөрәҗәгать итүчедән мондый документ яки мондый күчермәне хокук билгеләүче документны тапшыру турында хәбәрнамә җибәргәннән соң 15 календарь көн эчендә алмаса;

г) әгәр бакча йорты яки торак йортка өченче затларның хокуклары булган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Нигезләмәнең 56 пунктындагы «г» пунктчасында каралган документны тапшырмау;

д) бакча йортын яки торак йортны Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төрләре мондый урнаштыруны күздә тотмый торган урнаштыру;

е) мөрәҗәгать итүче яки башка зат тарафыннан даими яшәү урыны буларак торак йортны куллану (торак йортны бакча йорты дип тану турындагы гаризаны караганда)».

9. «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт» баганасының 2.9 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«Нигезләмәнең 56 пункты».

10. 3 бүлекнең 3.5.1. пунктында «соратуларга җаваплар алган мизгелдән соң» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар соратуларга җавап алганнан соң 7 көн эчендә гамәлгә ашырыла».

11. 3 бүлекнең 3.5.2 пунктында 7, 8 абзацларны төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура комиссиягә документлар кергән вакыттан алып 20 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура комиссиягә документлар кергән вакыттан алып 25 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Нигезләмәдә яки бинаны карап тикшерү турында билгеләнгән торак бинаны туры килә (туры килми), бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында карар.».

12. 3.6.1 пунктында 5, 6 абзацларны төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләмә кергән вакыттан алып 6 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура бәяләмә кергән вакыттан алып 10календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә имза салуга юнәлдерелгән боерык проекты».